# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР №24**

III чакырылыш XXXII утырышы  Уруссу ш.т.б.  2020 елның 26 мае

**Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2009 елның 11 мартындагы «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында 7 санлы һәм 2020 елның 17 мартындагы «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында 13 санлы карарларын юкка чыгару турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» 18 санлы карары белән кабул ителгән муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы

К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2009 елның 11 мартындагы «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында 7 санлы һәм 2020 елның 17 мартындагы «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында 13 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлекләре советлары белән законлылык, регламент һәм үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **З.М. Аглиева**